ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«ЛЕНИНОГОРСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2024 г.Лениногорск № 1390

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 18 ноябрендәге 1080 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар уздырмыйча милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 18 ноябрендәге 1080 номерлы карары белән расланган Муниципаль милектәге җир кишәрлеген торглар уздырмыйча милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3.4.4 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.4. Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны техник мөмкинлек булганда башкару дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат

системасын кулланып, шул исәптән гаризаны регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән вакыттан алып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән аерым процедураларны үтәү кысаларында, һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле, пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт Географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.»;

3.4.5. пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.5. Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны техник мөмкинлек булганда башкару дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, шул исәптән гаризаны регламентның 2.13 пункты нигезендә теркәгән вакыттан алып автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.4.2, 3.4.4, 3.4.5 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

3.5.6. пуктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.5.6. Регламентның 3.5.3-3.5.5 пунктларында күрсәтелгән процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Регламентның 3.5.3 - 3.5.5 пунктларында күрсәтелгән һәм шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле аерым процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасын куллану рөхсәт ителә.»;

түбәндәге редакциядә 3.5.7 пунктны өстәргә:

«3.5.7. Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы 14 эш көне, җир кишәрлеге биреләчәк дигән хәбәр басылып чыккан очракта - 47 эш көне.»;

3.6.2. пуктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.6.2. Документны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документациясен алып бару ярдәмче системасына һәм (яисә) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итүнең

мәгълүмати системасына муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә белешмәләрне теркәүне һәм кертүне тәэмин итә;

гаризада күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен органда яисә КФҮтә алу мөмкинлеге турында хәбәр итә.

Процедураларны үтәү техник мөмкинлекләр булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасын кулланып, автомат режимда башкарыла.

Шул исәптән пространство белешмәләреннән файдалануга бәйле процедураларны үтәү кысаларында пространство белешмәләренең милли системасы эшчәнлеген тәэмин итә торган федераль дәүләт географик мәгълүмат системасыннан файдалану рөхсәт ителә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган административ процедуралар органның вәкаләтле вазыйфаи заты (орган) тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (бирүдән баш тартуны) раслый торган документка имза салынган көннән алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат системаларында белешмәләрне урнаштыру, мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе һәм аны алу ысуллары турында хәбәр итү административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора.».

2. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), гражданнар күзәтә алырлык мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Лениногорск муниципаль районы»муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче М.Н.Гирфанов

Галимова Л.М.
5-44-72